Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советы
карары

2021 елның 28 апреле № 9/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советының «Җир салымы ставкаларын кертү, аларның исемлеген билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 21/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай Выселкасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советының «Җир салымы ставкаларын билгеләү, аларның тәртибен һәм аларны түләү срокларын гамәлгә кертү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 21/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар исемендә «һәм сроклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карарны күп кеше йөри торган урыннарда мәгълүмат стендларында элү һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар җир салымы түләүгә һәм җир салымы буенча аванс түләүләре түләүгә бәйле рәвештә 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләсе буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Чистай муниципаль районының
Чистай Выселкасы авыл җирлеге башлыгы _______________ С.А.Ефимов